ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_10.01.2023_ Мөслим авылы № _6__

**«Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, түләүсез нигездә файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 3 ноябрендәге 500 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Җир кодексы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» 236 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән сатулар үткәрмичә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 3 ноябрендәге 500 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8.2.1 пунктының 13 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеген шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык эшен алып бару яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирү турында хәбәрнең басылып чыгуы һәм урнаштырылуы;»

1.2. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган мөрәҗәгатьне формат-логик яктан тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гариза бирүче электрон формадагы мөрәҗәгатьнең һәр юлын тутырган вакытта автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы мөрәҗәгатьтә тиешенчә тутырылмаган юл ачыкланганда, ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гариза бирүчегә мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмати хәбәр ярдәмендә хәбәр ителә».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**